**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге Сатлыган авылында гражданнарга үзара салым кертү турында**

09 нчы декабрь 2024 ел № 3

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сатлыган авылында гражданнар җыены **карар итте** :

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Салтыган авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, ташламалы категориялардән тыш (беренче төркем инвалидлары, көндезге формада укучы студентлар) һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәгеләрне үтәү буенча юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;

-ремонт, киртәләр төзү, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

- җайланмалар, коеларны ремонтлау һәм янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Салтыган авылы, Урта урамы, 1 нче йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә урнаштырырга

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Уразлы авыл җирлеге башлыгы: М.Г.Хәмидуллин